| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 29.08.2025 | п.г.т. Алексеевское | № 339 |

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 14.09.2018 ел, № 196 «Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларына ташламалы аренда билгеләү, арендага бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Алексеевск районы прокуратурасының 19.06.2025 № 02-08-01-2025/278-25-20920006 протестын карап

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 14.09.2018 ел, № 196 «Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларына ташламалы аренда билгеләү, арендага бирү тәртибен раслау турында» карары белән расланган,Алексеевск муниципаль районы муниципаль милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларына ташламалы аренда билгеләү, арендага бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертерә:

1) 1нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- мәдәни мирас объектын канәгатьләнерлек хәлдә булмаган мәдәни мирас объектларына кертү Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә канәгатьләнерлек булмаган хәлдә урнашкан мәдәни мирас объектларына кертү критерийлары нигезендә;

2) 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- аукцион «Дәүләт милкенә яисә муниципаль мөлкәткә карата хокуклар күчүне күздә тоткан башка шартнамәләр, аренда шартнамәләре, мөлкәткә ышаныч белән идарә итү шартнамәләре, башка шартнамәләр төзү хокукына конкурслар яисә

аукционнар уздыру тәртибе турында» 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы Федераль монополиягә каршы хезмәт боерыгы һәм күрсәтелгән шартнамәләрне төзү конкурс рәвешендә сату уздыру юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге нигезендә уздырыла»;

3) 7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- мәдәни мирас объектын канәгатьләнерлек хәлдә дип танудан баш тарту өчен нигез булып мәдәни мирас объектының Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында" 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә мәдәни мирас объектларына кертү критерийларына туры килмәве тора.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе Э.Н.Павловага йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **С. А. Демидов**